

12 нче февраль-дә Мордовиянен торле почмакларында «Россиянен чангы юллары - 2022» Ботенроссия ярышлары узды, анда сарансклылар да, республиканын башка жирләрен-нән килгән спорт соючеләр дә катнашты.

«Россиянен чангы юллары - 2022» «Демография» илкvләм проектынын «Спорт - тормыш нормасы» федераль программасы кысаларында vткәрелә. Сарансктагы чанга-биатлон комплексы территориясендә vткән ярышта 1500 кеше катнашты, ә республикабыз районнарында катнашучылар саны 2500дән дә артык булган дип исәплиләр.

Гадәттәгечә, чарада һәвәскәрләр, спортчылар-профессионаллар, спорт ветераннары, сәяси һәм дәvләт эш-лекләләре, хезмәт коллективлары катнашты. Быел, Мордовия башкаласында кешеләр кvп жыелу сәбәпле, эпидемиологик хәл аркасында, ярышлар массакvләм стартларсыз узды. Катнашучылар вакытлы интервал белән торкемнәр белән старт алды. Спорт соючеләр vз кочләрен 3 һәм 5 километр дистанцияләрдә сынап карый алдылар. Тамашачыларга кызыклы бәйрәм программасы тәкъдим ителгән, ә тунып-ачыгып олгергәннәргә традицион ботка һәм чәй тәгъдим иттеләр.

Вип-йогерештә хатын-кызлар арасында Наилә Прянкова, Ольга Игошева, Ирина Паршина һәм ир-атлар арасында Михаил Трофимов, Александр Красников һәм Сергей Вдовин ин житезләре булдылар. Барлык жинvчеләр һәм призерлар медальләр, ә алар кvбәv булды, Россия Спорт министрлыгы кубоклары һәм грамоталары, «Бердәм Россия» партиясенен региональ бvлекчәсе һәм Мордовия Республикасынын «Минем бизнес» vзәге истәлекле призлары белән бvләкләнде.

Ә районнарга килгәндә, Ромоданово районында vткән ярышларда “Ромодановская СОШ №1” мәктәбе 7Б сыйныф укучысы Асаинов Адель белән анын физкультура укытучысы Е.Е.Огай катнашканнар: алар алдынгылар рәтендә булганнар. Молодцы!

**Н.ХӘЛИЛ**